Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ:

10.10. 2022 ел № 5

“Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегендә
Кече Сөнчәле авылында гражданнарның үзара салымын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Сөнчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР бирәм:

1. 2022 елның 20 октябрендә 16 сәгать 00 минутка клуб бинасында түбәндәге адрес буенча : ТР, Аксубай муниципаль районы, Кече Сөнчәле авылы, Гагарин урамы, 38, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елда Аксубай муниципаль районы Кече Сөнчәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан тыш:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Кече Сөнчәле авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Бистә эчендәге юлларны ремонтлау (чүп ташы, туфрак һәм вак таш салу һәм тигезләү.

Торак пунктлар чикләрендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урам утларын агымдагы ремонтлау, урам яктырткычлары сатып алу;

Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- Кече Сөнчәле бистәсендәге су башнясын буяу;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Сөнчәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә: http:/aksubayevo.tatarstan.ru.һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы И.В. Крайнова

СОВЕТ СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ